Минем бабам, Байчурин Заһидулла Хосәен улы, 1917 елда Атюрьево районынын Татар Тенишево авылында туган. 1941 елнын 8 августында Боек Ватан сугышында катнашкан. Мордва АССРнын Атюрьево РВК-сыннан мобилизациялэнгэн. 1945 елнын 8 ноябрендэ демобилизациялэнгэн.   1941 елда Боек Ватан сугышы кырларында фашистларга каршы барган сугышларнын берсендэ кулы каты яралана. Санчастьтэ дэваланудан сон сафка кайта һэм Берлинга кадэр, дошманны куа-куа, барып житэ. Укчы, сержант, бvлек командиры, аннары взвод командиры булып хезмэт итэ. Орденнары һэм медальлэре бар.
Бабаем Хосэен улы Заһидулла Байчурин Боек Ватан сугышыннан фашистны жинvче инвалид булып кайта. Атюрьево районы «Коммунар» колхозында хужалык модире, аннары рэис урынбасары булып эшли. 1967 елда вафат була.
Минем бабаем сугышны кичерде. Кызганычка каршы, мин анын белэн очраша алмадым, эмма энием анын турында кvп сойли торган иде. Мин бабаем Заһидулла Хосэен улы белэн горурланам, ул vзенен батырлыгы белэн фашистларны Жинvне якынайтырга ярдэм итте, һэм мин тыныч кvк астында тудым һэм яшим!

Эльвира СОВЕШОВА, □ *2 Атюрьево мэктэбе директоры кинэшчесе*